КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1234

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче, 2015 ел, 12 сентябрь, 669 нчы, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы, 2020 ел, 28 гыйнвар, 40 нчы, 2020 ел, 31 гыйнвар, 51 нче, 2020 ел, 24 февраль, 131 нче, 2020 ел, 24 март, 217 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләре һәм тәртибенenә 3 нче кушымтага, 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гаиләнең барлык әгъзаларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булмау турында салым органының белешмәсе.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 ел, 27 декабрь, ТРЗ-69 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 ел, 2 август, 366 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 8 октябрь, 543 нче; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 14 май, 321 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2013 ел, 29 октябрь, 806 нчы; 2015 ел, 15 гыйнвар, 7 нче; 2015 ел,

13 апрель, 250 нче; 2016 ел, 19 август, 576 нчы, 2016 ел, 5 декабрь, 892 нче, 2017 ел, 30 сентябрь, 740 нчы, 2020 ел, 31 гыйнвар, 51 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

алтынчы абзацта «20» саннарын «30» саннарына алмаштырырга;

җиденче абзацта «20 проценттан артык» сүзләрен «30 проценттан артык» сүзләренә алмаштырырга, «(шул исәптән 20 процент)» сүзләрен «(шул исәптән 30 процент)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль ипотека буенча торак сатып алу өчен гражданнарның түләүләр шартларын һәм срокларын билгеләү тәртибенә 1 нче кушымтага искәрмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Артыклык коэффициентларын билгеләү һәм республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 03 февраль, 53 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 апрель, 250 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), 1 пунктта “1,5” саннарын “1,2” саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 13 июль, 587 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибенә 2 нче кушымтага, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гаиләнең барлык әгъзаларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булмау турында салым органының белешмәсе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин